ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 августа 2021г. № 5091

«2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» муниципаль программасы турында

Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче хәзерге һәм киләчәк буынның сәламәтлеген югары дәрәҗәгә җиткерү, шул исәптән халыкның үз сәламәтлегенә җаваплы мөнәсәбәтен формалаштыру, Яр Чаллы шәһәрендә сәламәт яшәү рәвеше алып бару, кеше потенциалын саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыру максатында, Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгы тарафыннан эшләнгән «Демография» илкүләм проекты, «Сәламәт туклануны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, гражданнарның сәламәт яшәү рәвешен мотивацияләү системасын формалаштыру» «Иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» федераль проекты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 2 августындагы
5091 номерлы карарына
кушымта

«2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту»
муниципаль программасы

## 1 бүлек. «2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» муниципаль программасы паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» муниципаль программасы (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 31 декабрендәге 683 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясенең Илкүләм куркынычсызлык стратегиясе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 17 ноябрендәге 1662-р номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясенең 2020 елга кадәр чорга озак сроклы социаль-икътисадый үсеш концепциясе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 25 октябрендәге 1873-р номерлы боерыгы белән расланган 2020 елга кадәр чорга халыкның сәламәт туклану өлкәсендә Россия Федерациясенең төп дәүләт сәясәте нигезләре, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 29 ноябрендәге 2539-р номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясендә 2025 елга кадәр өлкән буын гражданнар мәнфәгатьләрендә гамәлләр стратегиясенең беренче этабын тормышка ашыру буенча 2016-2020 елларга чаралар планы, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «2025 елга кадәр чорга Халыкның сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, йогышлы булмаган авыруларны профилактикалау һәм контрольдә тоту стратегиясен раслау турында» 2020 елның 15 гыйнварындагы 8 номерлы приказы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе, Башкарма комитетның районнар хакимиятләре, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе |
| Программаның максаты | Халык сәламәтлеген, аларның тормыш сыйфатын яхшырту, иҗтимагый сәламәтлек культурасын, сәламәтлеккә җаваплы караш формалаштыру |
| Программаның бурычлары | - халыкта сәламәт яшәү рәвешен алып баруга, начар гадәтләрдән баш тартуга мотивация формалаштыру;<br>- халыкны даими медицина тикшерүе үткәрү юлы белән авыруларны профилактикалау;<br>- оптималь хәрәкәт режимын һәм дөрес туклану режимын формалаштыруда ярдәм итү;<br>- организмның әйләнә-тирә мохитнең зарарлы йогынтысына, стрессларга тотрыклылыгын арттыру, иртә балачактан сәламәт гадәтләр һәм күнекмәләрне үстерү, үз хис-тойгыларын үти белү;<br>- авыруларны профилактикалау һәм үз сәламәтлегеңне саклау һәм |

| | |
|---|---|
| | ныгыту чаралары турында халыкка мәгълүмат бирү системасын үстерү |
| Программаны тормышка ашыру срогы | 2021-2025 еллар |
| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны тормышка ашыруга акча бүлеп бирү каралмаган |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | - физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче халыкның чагыштырма авырлыгын арттыру;<br>- гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләүгә юнәлдерелгән оештырылган мәгълүмати-коммуникацион компанияләр санын арттыру;<br>- сәламәт яшәү рәвеше мәсьәләләре буенча медицина оешмаларына мөрәҗәгать итү санын арттыру;<br>- симерү белән бәйле авырулар саны артуны киметү;<br>- вакытлыча эшкә яраксызлык очракларының санын киметү;<br>- сәламәтлек үзәкләрендә сәламәт яшәү рәвеше буенча индивидуаль планнар (сәламәтлек паспортлары) тәкъдим ителгән затлар саны;<br>- халыкны диспансеризацияләү күләмен арттыру;<br>- физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар өлешен арттыру |
| Программаны тормышка ашыруга контрольне оештыру системасы | Программа үтәлешенә гомуми контрольне Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе гамәлгә ашыра. |

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Программа Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан эшләнгән «Демография» илкүләм проекты, «Сәламәт туклануны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләү системасын формалаштыру» «Иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» федераль проекты нигезендә, Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче хәзерге һәм киләчәк буынның сәламәтлеген югары дәрәҗәгә җиткерү, шул исәптән халыкның үз сәламәтлегенә җаваплы мөнәсәбәтен формалаштыру, шәһәрдә сәламәт яшәү рәвеше алып бару, кеше потенциалын саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыру максатында эшләнде.

Программаның актуальлеге ачык, чөнки төрле чыганаклар буенча кеше сәламәтлегенә, аның гомер озынлыгына барлык йогынтының 60% ы – аның яшәү рәвеше. Сәламәтлек торышы ул – социаль, икътисадый һәм экологик иминлекнең мөһим күрсәткече, Яр Чаллы шәһәре халкының тормыш сыйфаты күрсәткече.

Йогышлы булмаган авырулар дөньяда, шулай ук Россия Федерациясендә вакытлыча эшкә яраксызлык, инвалидлык һәм халык үлеменең төп сәбәбе булып тора.

Йогышлы булмаган авыруларга йөрәк-кан тамырлары авырулары, яман шешләр, сулыш органнарының хроник авырулары һәм шикәр диабеты керә.

2020 ел йомгаклары буенча Яр Чаллы шәһәрендә диспансеризацияләү һәм профилактик тикшерүләр нәтиҗәләре буенча ачыкланган авырулар структурасында беренче урында – кан әйләнеше системасы авырулары (969 кеше – 42 %), икенче урында – эндокрин системасы авырулары, туклану бозылу һәм матдәләр алмашы бозылулар (390 кеше – 17 %), өченче урында – сөяк-мускул системасы авырулары (377 кеше – 16,3 %), дүртенче урында – аш кайнату органнары авырулары (260 кеше – 1 1,2 %) тора.

Йогышлы булмаган авырулардан үлүчеләр санының югары дәрәҗәдә булуы медицина ярдәме (шул исәптән югары технологияле) күрсәтү өчен турыдан-туры чыгымнарга бәйле зур икътисадый югалтуларга, шулай ук вакытыннан алда үлем, инвалидлык һәм вакытлыча эшкә яраксызлык аркасында хезмәт ресурсларын кыскарту нәтиҗәсендә икътисадый югалтуларга китерә.

Йогышлы булмаган авыруларны профилактикалауның һәм контрольдә тотуның нигезе булып сәламәт яшәү рәвеше тора. Сәламәт яшәү рәвеше – кешенең йогышлы булмаган авырулар барлыкка килүне һәм аның үсешен кисәтүгә юнәлдерелгән һәм үз-үзеңне тотудагы куркыныч факторларның (алар исәбенә рациональ булмаган туклану, физик активлык булмау, шулай ук стрессларны адаптив булмаган рәвештә җиңү керә) булмавы яки кимүе белән характерлана торган яшәү рәвеше ул.

2020 ел башына шәһәрдә даими яшәүче халык саны 533839 кеше тәшкил итте, бу 2019 ел саныннан 0,01% ка кимрәк.

2019 ел белән чагыштырганда, халыкның гомуми структурасында балаларның өлеше 0,9% ка, эшкә яраклы халык өлеше 1,2% ка арту күзәтелә. Шул ук вакытта пенсия яшендәге халык өлеше 3,1% ка кимегән. 2020 ел йомгаклары буенча Яр Чаллы шәһәрендә халыкның табигый үсеш күрсәткече - 1000 кешегә 0,6 тәшкил итте.

Соңгы биш елда чаллылыларның көтелгән гомер озынлыгы 1,1 елга арткан (2016 – 74,7; 2017 - 74,8; 2018 - 75,14; 2019 - 75,2), 2020 ел йомгаклары буенча 75,8 ел тәшкил иткән.

Ачыкланган авырулар структурасында лидерлык итүче күп кенә йогышлы булмаган авырулар барлыкка килүгә йогынты ясый торган куркыныч факторлар булып гиподинамия, рациональ булмаган туклану, артык психик көчәнеш, стресслар, начар гадәтләр, артык тән массасы тора.

Хәзерге вакытта организмда май тукымасы күләменең патологик артуы (симерү) эстетик проблема кысаларыннан чыга һәм күп кенә авыр, еш кына – элекке хәленә кайтмый һәм үлемгә китерә торган авырулар үсешенең сәбәбе булып тора.

Хәзерге вакытта Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләр арасында симерүнең һәм артык тән массасының таралу күрсәткече 1000 кешегә 4,2 тәшкил итә, ягъни 2265 кеше, артык тән массасы яки симерү белән интегүче, эшкә яраклы халык арасында 3% тан артык.

Төрле чыганаклар мәгълүматлары буенча, хәзерге вакытта Россиядә симерүдән интегүче кешеләрнең 95% ы турыдан-туры тән массасы белән бәйле сәбәпләрдән үлә. Симерү белән авыручыларның гомер озынлыгы 10-20 елга кими (симерү үсешенең елына карап).

Хәзерге һәм киләчәк буынның сәламәтлек дәрәҗәсен халык сәламәтлеген ныгытуга һәм әйләнә-тирә мохитне савыктыруга юнәлдерелгән сәясәт формалаштыру аша, кешеләрнең үз сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирәдәгеләрнең сәламәтлегенә җаваплы карашын формалаштыру аша күтәрергә мөмкин.

Болар барысы да комплекслы якын килүне: төрле ведомстволарны берләштерүне, эшчәнлеге тормыш һәм сәламәтлек сыйфатына йогынты ясаучы барлык милек формаларын, гражданлык җәмгыятен оештыруны; халык сәламәтлеге проблемаларын хәл итү максатларында максатчан һәм килешенгән хезмәттәшлекнең тотрыклы системасын төзүне таләп итә.

Шулай итеп, Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләр тарафыннан сәламәт яшәү рәвешен алып бару үлем очракларының кимүенә, шул исәптән хезмәткә яраклы халык арасында, зурлар һәм балалар арасында авыруларның кимүенә, инвалидлык буенча пенсиягә вакытыннан алда чыгу ихтималларының кимүенә, авыруларны кисәтүгә һәм авыруларны иртә стадияләрдә ачыклауга йогынты ясаячак. Халыкның сәламәт яшәү рәвеше, сәламәтлек саклау өлкәсендәге югары күрсәткечләр «Демография» илкүләм проектының максатчан күрсәткеченә ирешүгә – көтелгән сәламәт яшәү дәвамлылыгының 67 яшькә кадәр артуына; күчмә миграцияне киметүгә һәм туучылар санын арттыруга китерәчәк, бу исә Яр Чаллы шәһәрендәге гомуми демографик хәлгә уңай тәэсир итәчәк.

Программаны тормышка ашыруның финанс-икътисадый нәтиҗәсе булып, эшкә яраклы халык саны арту, эшкә яраксызлык кәгазьләре буенча түләүләр кимү, эшкә яраксызлык вакыты кимү (шул исәптән авыру балалар өчен) хисабына Яр Чаллы шәһәре бюджетына физик затлар кеременә салым арту торачак.

## 3 бүлек. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаны тормышка ашыру 5 елга – 2021-2025 елларга исәпләнгән.

Муниципаль программаның максаты булып халык сәламәтлеген, аларның тормыш сыйфатын яхшырту, иҗтимагый сәламәтлек культурасын, сәламәтлеккә җаваплы караш формалаштыру тора.

Программаның бурычлары булып тора:

- физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче халыкның чагыштырма авырлыгын арттыру;
- гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләүгә юнәлдерелгән оештырылган мәгълүмати-коммуникацион компанияләр санын арттыру;
- сәламәт яшәү рәвеше мәсьәләләре буенча медицина оешмаларына мөрәҗәгать итү санын арттыру;
- симерү белән беренчел авырулар саны артуны киметү;
- вакытлыча эшкә сәләтсезлек очракларының санын киметү;
- сәламәтлек үзәкләрендә сәламәт яшәү рәвеше буенча индивидуаль планнар (сәламәтлек паспортлары) тәкъдим ителгән затлар саны;
- халыкны диспансеризацияләү күләмен арттыру;
- физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар өлешен арттыру.

## 4 бүлек. Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген билгеләргә мөмкинлек бирүче индикаторлар

Куелган бурычларны программа чараларын тормышка ашыру ярдәмендә хәл итү нәтиҗәлелеге ел саен мониторинг ярдәмендә, программа нәтиҗәлелегенең билгеләнгән күрсәткечләренә ирешү юлы белән бәяләнә:

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү методикасы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1. | Гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләүгә юнәлдерелгән оештырылган мәгълүмати- | N – сан | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе мәгълүматы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | коммуникацион компанияләр санын арттыру | | |
| 2. | Сәламәт яшәү рәвеше мәсьәләләре буенча медицина оешмаларына мөрәҗәгать итү (мең кеше) | Күрсәткеч 0-17 яшьлек балаларның һәм 18 яшьтән өлкән затларның (мең кеше) яшәү рәвеше белән бәйле проблемалар буенча медицина оешмаларына килү санының суммасы буларак исәпләнә:<br>$S_{oz} = S_{0\text{-}14} + S_{15\text{-}17} + S_{18}$<br>монда:<br>$S_{0\text{-}14}$ – 0-14 яшьлек балаларның яшәү рәвеше белән бәйле проблемалар буенча медицина оешмаларына килү саны, мең кеше;<br>$S_{15\text{-}17}$ – 15-17 яшьлек балаларның яшәү рәвеше белән бәйле проблемалар буенча медицина оешмаларына килү саны, мең кеше;<br>$S_{18}$ – 18 яшьтән өлкән затларның яшәү рәвеше белән бәйле проблемалар буенча медицина оешмаларына килү саны, мең кеше;<br>$S_{oz}$ - яшәү рәвеше белән бәйле проблемалар буенча медицина оешмаларына мөрәҗәгать итү саны (мең кеше). | Росстатның 2018 елның 24 декабрендәге 773 номерлы приказы белән расланган «Медицина оешмасына хезмәт күрсәтү районында яшәүче пациентларда теркәлгән авырулар саны турында мәгълүматлар» 12 номерлы федераль статистик күзәтү формаларының мәгълүматлары |
| 3. | Симерү белән беренчел авырулар саны арту темплары (%) | Күрсәткеч тикшерелә торган чорда һәм база чорларында симерү белән беренчел авыру очраклары санының чагыштырмасы (%) буларак, түбәндәге формула буенча исәпләнә:<br>$Tp = \left(\frac{Pip}{Pbp} * 100\right) - 100\%$<br>монда:<br>Pip – тикшерелә торган чорда симерү белән беренчел авыру очраклары саны;<br>Pbp – база чорында симерү белән беренчел авыру очраклары саны;<br>Tp – симерү белән беренчел авыру арту темплары (%). | Росстатның 2018 елның 24 декабрендәге 773 номерлы приказы белән расланган «Медицина оешмасы турында мәгълүматлар» 12 номерлы федераль статистик күзәтү формаларының мәгълүматлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Вакытлыча эшкә яраксызлык очракларының саны (1 мең кешегә) | Күрсәткеч хисап чорында Россия Федерациясе халкы санына карата барлык сәбәпләр буенча вакытлыча эшкә яраксызлык очракларының чагыштырмасы буларак исәпләнә (мең кешегә очраклар саны): $$Svn = \frac{Svnvp}{S} * 1000$$ монда: $Svnvp$ - барлык сәбәпләр буенча вакытлыча эшкә яраксызлык очракларының саны; S – хисап чорында Россия Федерациясе халкы саны, кеше; $Svn$ - 1 мең кешегә вакытлыча эшкә яраксызлык очракларының саны. | Росстатның 2014 елның 25 декабрендәге 723 номерлы приказы белән расланган «Вакытлыча эшкә яраксызлык сәбәпләре турында мәгълүматлар» 16-ВН номерлы федераль статистик күзәтү формаларының мәгълүматлары |
| 5. | Сәламәтлек үзәкләрендә сәламәт яшәү рәвеше буенча индивидуаль планнар (сәламәтлек паспортлары) тәкъдим ителгән затлар саны (млн. кеше) | Күрсәткеч 0-17 яшьлек балаларның һәм 18 яшьтән өлкән затларның (миллион кеше) сәламәтлек үзәкләренә беренчел килү санының суммасы буларак исәпләнә: $Spz=S_{0-17}+S_{18+}$ монда: $S_{0-17}$ - 0-17 яшьлек балаларның сәламәтлек үзәкләренә беренчел килү саны, миллион кеше; $S_{18+}$ - 18 яшьтән өлкән затларның сәламәтлек үзәкләренә беренчел килү саны, миллион кеше; Spz – сәламәтлек үзәкләрендә сәламәт яшәү рәвеше буенча индивидуаль планнар (сәламәтлек паспортлары) тәкъдим ителгән затлар саны (млн. кеше) | Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2009 елның 19 августындагы 597н номерлы приказы белән расланган «Сәламәтлек үзәге эшчәнлеге турында мәгълүматлар» 68 номерлы тармак статистик күзәтү формаларының мәгълүматлары |
| 6. | Халыкны диспансеризацияләү күләмен арттыру | Күрсәткеч зурлыгы диспансеризация узган затлар санына карата диспансеризация узарга кирәк булган затларның фактагы саныннан чыгып исәпләнә. $$K = \frac{a}{b} \cdot 100$$ , | «Республика медицина-мәгълүмат үзәге» ДАССУның статистик мәгълүматлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | монда, *K* – кирәкле күрсәткеч, *a* – процентларда күрсәтергә кирәкле очраклар саны; *b* - 100% дип кабул ителә торган очракларның гомуми саны. | |
| 7. | Физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар өлеше | ДОВЗ = СЗС/ОВЗ, монда ДОВЗ - физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар өлеше, СЗС – сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр саны, ОВЗ – сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән затларның гомуми саны | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе мәгълүматы |

5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны тормышка ашыруга акча бүлеп бирү каралмаган.

6 бүлек. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү, программаны тормышка ашыру тәмамланганнан соң, хисап финанс елында һәм тулаем алганда, аның үтәлеше йомгаклары буенча башкаручы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Программаны гамәлгә ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелегенә түбәндәгеләр хисабына ирешеләчәк:

- Яр Чаллы шәһәрендә халык сәламәтлеген саклауга һәм яхшыртуга ярдәм итүче ведомствоара мөнәсәбәтләрнең яңа системасын булдыру;
- Яр Чаллы шәһәре халкына куркыныч янаучы факторлар һәм авыруларны профилактикалау турында мәгълүмат бирү системасын көчәйтү;
- авыруларны профилактикалауга, сәламәт яшәү рәвешен җәелдерүгә бәйле граждannар, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар инициативаларының санын арттыру;
- демографик хәлне яхшырту, уртача гомер озынлыгын арттыру, Яр Чаллы шәһәрендә вакытыннан алда үлүчеләр, авырулар санын, халыкның инвалидлыгын киметү өчен шартлар тудыру.

## 7 бүлек. Программа чаралары

### «2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» муниципаль программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау

| Төп чараның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Значение индикаторов | | | | | | | Финансирование (тыс. руб.) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 ел (база) | 2020 ел (якынча) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| Максат: Халык сәламәтлеген, аларның тормыш сыйфатын яхшырту, иҗтимагый сәламәтлек культурасын, сәламәтлеккә җаваплы караш формалаштыру | | | | | | | | | | | | | | | |
| I. Халыкта сәламәт яшәү рәвешен алып баруга, начар гадәтләрдән баш тартуга мотивация формалаштыру | | | | | | | | | | | | | | | |
| Халыкның төрле максатчан төркемнәре өчен, сәламәт туклануны, хәрәкәт активлыгын һәм начар гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләүгә юнәлдерелгән мәгълүмати-коммуникацион кампанияләр оештыру | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2021-2025 еллар | Чаралар саны, берәмлек | 20 | 20 | 40 | 50 | 50 | 50 | 50 | Чара оештыру характерына ия | | | | |
| Халык арасында сәламәтлек үзәкләрен популярлаштыруны оештыруда ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2021-2025 еллар | Сәламәтлек үзәкләрендә сәламәт яшәү рәвеше буенча индивидуаль планнар (сәламәтлек паспортлары) тәкъдим ителгән затлар санын арттыру, берәмлек (яңа затлар хисабына) | 12368 | 12368 | 12368 | 12368 | 12368 | 12368 | 12368 | Чара оештыру характерына ия | | | | |
| Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы тарафыннан расланган халыкара һәм бөтендөнья даталарны исәпкә алып, массакүләм тематик профилактик акцияләрдә катнашу: | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | 2021-2025 еллар | Вакытлыча эшкә яраксызлык очракларының санын кимету | 255,3 | 368,6 | 350,0 | 320,0 | 290,0 | 250,0 | 230,0 | Чара оештыру характерына ия | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бөтендөнья гипертониягә каршы көрәш көне (17.05);<br>- Бөтендөнья йөрәк көне (29.09);<br>- Бөтендөнья аеклык көне (03.10);<br>- Бөтендөнья инсультка каршы көрәш көне (29.10);<br>- Бөтендөнья шикәр диабетына каршы көрәш көне (14.11) | | | (1 мең кешегә) | | | | | | | | |
| Сәламәт яшәү рәвешен алып бару буенча шәхси позицияне формалаштыруга юнәлдерелгән проектларга, идеяләргә һәм программаларга (шул исәптән яшьләр) ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2021-2025 еллар | Сәламәт яшәү рәвеше мәсьәләләре буенча медицина оешмаларына мөрәҗәгать итүне арттыру, берәмлек | 11450 | 6830 | 9100 | 11300 | 11800 | 12000 | 12600 | Чара оештыру характерына ия |
| II. Оптималь хәрәкәт режимын һәм дөрес туклану режимын формалаштыруда ярдәм итү | | | | | | | | | | | |
| Җәйге чорда мәктәп яны, сәламәтләндерү лагерьларын оештыру | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2021-2025 еллар | Симерү белән беренчел авырулар саны артуны киметү, процент | 70 | -22,8 | 70 | 65 | 60 | 55 | 50 | Чара оештыру характерына ия |
| Шәһәрнең белем бирү оешмаларында «Сәламәт туклану» темасына бердәм ачык дәресләр үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2021-2025 еллар | Симерү белән беренчел авырулар саны артуны киметү, процент | 70 | -22,8 | 70 | 65 | 60 | 55 | 50 | Чара оештыру характерына ия |
| Яшәү урыны буенча төрле яшьтәге халык катнашында, эшләүчеләр, хезмәткәрләр һәм яшьләр арасында физкультура-сәламәтләндерү һәм массакүләм спорт чаралары (спорт ярышлары, спорт эстафеталары) үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | 2021-2025 еллар | Массакүләм спорт һәм сәламәтләндерү чараларында катнашучылар санын арттыру | | | | | | | | Чара оештыру характерына ия |
| Физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында спорт эшен оештыру, адаптив физик культура һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | 2021-2025 еллар | Физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче физик мөмкинлекләре | | 19,5 | 20,5 | 21 | 21,5 | 22 | 22,5 | Чара оештыру характерына ия |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | чикләнгән затлар өлеше, әлеге категория халыкның гомуми санында, % | | | | | | | | |
| III. Халыкны даими медицина тикшерүе үткәрү юлы белән авыруларны профилактикалау | | | | | | | | | | | |
| Балаларга һәм зурларга профилактик медицина тикшерүләре үткәрүдә ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | 2021-2025 еллар | Халыкны диспансеризацияләү күләме, процент | | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Чара оештыру характерына ия |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева